КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 19 июнь г.Казань № 437

Төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экология экспертизасы узарга тиешле әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге документлар проектлары исемлеген раслау турында

«Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 1 пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экология экспертизасы узарга тиешле әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге документлар проектлары исемлеген расларга.
2. Бу карар 2024 елның 1 сентябреннән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 19 июнь, 437 нче
карары белән расланды

Төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экология экспертизасы
узарга тиешле әйләнә-тирә мохитне саклау һәм
табигатьтән файдалану өлкәсендәге документлар проектлары
исемлеге

| Т/с | Төбәк дәрәҗәсендәге дәүләт экология экспертизасы узарга тиешле әйләнә-тирә мохитне саклау һәм табигатьтән файдалану өлкәсендәге документлар | Төбәк дәрәҗәсендәге объектларга дәүләт экология экспертизасын оештыруга һәм уздыруга вәкаләтле республика башкарма хакимият органы |
|---|---|---|
| 1. | Татарстан Республикасы территориясендә хайваннар дөньясы объектларын алу күләмнәрен (лимитларын, квоталарын) нигезләүче материаллар проектлары | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы |